**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Элмәле авылында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

**27 нче ноябрь 2020 ел** **Иске Элмәле** **№1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Иске Чүпрәле авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Иске Элмәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 октябрендәге 59/3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә, 2020 елның 27 ноябрендә тавыш бирү йомгаклары турында, 2020 елның 27 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 320 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-173, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның 54,06 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 173 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның 100% ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде, бу 0 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2020 елның 27 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының « Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Элмәле авылында гражданнар җыенын 2020 елның 27 ноябрендә уздырылган, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Иске Элмәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Иске Элмәледә урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;

- Колхоз, Культура, Комсомол, Космонавтлар, Пролетар, Яңа, Заречная, Иске Элмәле урамнары буенча юл-урам челтәрен ремонтлау;

- Иске Элмәледә зиратларны тоту;

- Иске Элмәледә карт агачларны кисү;

- Иске Элмәле авылында Пролетарская урамы буенча күперне ремонтлау дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип таныrга.

3. 2021 елда Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Иске Элмәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә.

- Иске Элмәледә урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;

- Колхоз, Культура, Комсомол, Космонавтлар, Пролетар, Яңа, Заречная, Иске Элмәле урамнары буенча юл-урам челтәрен ремонтлау;

- Иске Элмәледә зиратларны тоту;

- Иске Элмәледә карт агачларны кисү;

- Иске Элмәле авылында Пролетарская урамы буенча күперне ремонтлау

4. Халык җыены нәтиҗәләрен «Туган як " газетасында бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы,**

**Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы урынбасары,**

**халык җыенында рәислек итүче:** **Р.Д.Низамов**